**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**

Актүбә ш.т.б. № 25 «21» 06 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08.2015 № 20, 02.11.2015 № 10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 статьясы,15.04.2019 елдагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Уставы белән,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына18.08.2015 № 20, 02.11.2015 № 10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктның 5 пунктчасында. «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2. 3.2 пунктның 6 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк " газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatastan.ru. урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галеева